Республика Татарстан
Яурусовское сельское поселение
Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районынын
Янурыс авыл жирлеге

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

№6

01.10.2020

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата керемнәре турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Янурыс авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

2018 елның 10 августындагы № 6 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата керемнәре турында» Нигезләмәгәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәткәрләргә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладлары 11 498 сум тәшкил иткән күләмендәге, вазыйфаи окладлары билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU ) һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга .

3. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Янурыс авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе А. Ә.Мөхәммәдиева